МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

22.06.2020 г.Казань № 451

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 14 июлендә 6758 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгының 16.05.2016 ел № 261,

11.07.2018ел № 532, 08.05.2019 ел № 341, 14.11.2019 ел № 1030, 30.04.2020 ел № 279 боерыклары керткән үзгәрешләр белән) расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.А.Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин
итү һәм социаль яклау
министрлыгы боерыгы белән
расланды « 22 » 06 2020 № 451

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
«Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 17 июнендәге 419 номерлы боерыгы белән расланган
Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.3.4 пункттагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлыкның, халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең рәсми сайтында (http://www.mtsz.tatarstan.ru). Министрлыкның һәм халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган мәгълүматлар арасына әлеге Регламентның 1.3.3, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (пунктчалардагы) дәүләт хезмәте турында белешмәләр кертелгән;»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (аларның реквизитлары һәм рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) Министрлыкның, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренең рәсми сайтында, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.9 пунктта:

икенче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон» сүзләрен «1991 елның 19 апрелендәге 1032-1 номерлы «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» Россия Федерациясе Законы (алга таба –

Халыкны эш белән тәэмин итү турында Закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.2 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «524н номерлы Федераль стандарт» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2012 елның 13 ноябрендәге 524н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә, ә эш бирүчеләргә кирәкле хезмәткәрләрне сайлауда булышлык итүнең федераль дәүләт стандарты (алга таба - 524н номерлы Федераль стандарт)» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «19.02.2019 датасыннан 90н номерлы боерык» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 19.02.2019 датасыннан 90н номерлы «Халыкны эш белән тәэмин итүдә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» боерыгы (алга таба - 19.02.2019 датасыннан 90н номерлы боерык)» сүзләренә алмаштырырга, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 датасыннан 891 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 датасыннан 891 номерлы «Туры килә торган эш эзләү максатыннан гражданнарны теркәү, эшсез гражданнарны теркәү тәртибе һәм туры килә торган эшне сайлап алуга таләпләр турында» карары (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 датасыннан 891 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 07.09.2012 датасыннан 891 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пункттагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында бишенче абзацны үз көчен югалткан дип таныргa;

2.5 пункттагы «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Кулай эш эзләүдә ярдәм итү буенча дәүләт хезмәтен алу өчен, гариза бирүче (гражданин) халыкны эш белән тәэмин итү үзәгенә дистанцион рәвештә мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Моның өчен кулай эш эзләүдә ярдәм күрсәтү турында гаризаны электрон формада «Россиядә эш» Гомумроссия вакансияләр базасы мәгълүмати-аналитик системасының шәхси кабинетында яисә «Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасының шәхси кабинетында биреп була. (әлеге абзацның таләбе 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә)»;

2.5 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 8 апрелендәге 460 номерлы карары белән расланган Эшсезләр рәвешендәге гражданнарны кулай эш эзләү максатларында теркәүне, шулай ук билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләр бирүне көйләгән вакытлыча кагыйдәләрнең 2 нче пункты» сүзләрен өстәргә;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Хезмәтне яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында «09.07.1999 датасыннан 160-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «1999 елның 9 июлендәге 160-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләре турында» Федераль закон (алга таба - 09.07.1999 датасыннан 160-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Хезмәтне яисә таләпне билгеләүче норматив акт» графасында «601 номерлы Указ» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» Указы (алга таба - 601 номерлы Указ)» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 06.04.2011 датасыннан 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга.